**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1329 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 ноябрендәге 4140 номерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалана торган милекне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан арендалана торган, муниципаль милеккә караган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карарын исәпкә алып, гамәлдәге законнарга туры китерү, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, муниципаль хезмәтләрдән һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 ноябрендәге 4140 номерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалана торган милекне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан арендалана торган, муниципаль милеккә караган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 20 апрелендәге 1124 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), кушымтаның 2.9.3. пунктын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«2.9.3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалана торган милекне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан арендалана торган, муниципаль милеккә караган күчемсез милек өчен түләүне

кичектереп түләү срогы күчемсез милек өчен биш ел һәм күчемле милек өчен өч ел тәшкил итә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**